РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

26.12.2024 | № 1121-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 маендагы 578-п номерлы карары белән расланган сату-алуларда җир кишәрлеген арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 627-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының "Җир кишәрлеген арендага, торглардагы милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2021 елның 27 маендагы 578-п номерлы карары белән расланган җир кишәрлеген арендага, торглардагы милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәреш кертергә:

**1.1.** 2.8.2.1 пунктының 13 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13). җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән яисә территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән, аны гамәлгә ашыру Россия Федерациясе яисә Россия Федерациясе субъекты билгеләгән юридик зат тарафыннан Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы нигезендә тәэмин ителә торган территория чикләрендә урнашкан;".

**2.** Әлеге карар халыкка игълан ителгән мизгелдән үз көченә керә.

**3.** 5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

Җитәкче М. Р. Ишниязов